# Балалар бакчалары җитәкчеләре РМО беркетмәсе № 1

**Үткәрүвакыты**: 27.10.2019.
**Үткәрү урыны**: “Тылсым”мәктәп-балалар бакчасы.
**Катнашнашырга тиеш**: район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Хисматуллина Л.Ф., РМО җитәкчесе Аглямова М.В., балалар бакчалары мөдирләре, өлкән тәрбиячеләр.
**Катнашалар**: 42 бакча мөдире, 5 өлкән тәрбияче, РМО җитәкчесе Аглямова М.В., район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Хисматуллина Л.Ф.

**Тема**: Балалар бакчсында һөнәри стандартлар таләбен тормышка ашыру.

**Көн тәртибе:**

1. Проектлар парады. Күргәзмә.
2. Ачык мероприятияләр карау. Анализ.
3. Эш тәҗрибәсе белән уртаклашу (презентация).
4. Төрлеләр.

**Утырыш барышы**:

1 көн тәртибе буенча “Балаларның бизнес проекты” күргәзмәсе белән танышу.

2 нче көн тәртибе буенча практик эшчәнлек – шөгыльләр каралды. ТәрбиячеләрГильмутдинова В.Ф. зурлар төркеме белән “бөртек” тачысының сәяхәте” дигән темага шөгыль күрсәтте. Соңыннан максаты, бурычлары, балалар контингенты белән таныштырды. Үз анализ тәгъдим итте.

Анализ:

- № 1 балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе Сабирова Э.: “Тәрбияче шөгыльдә куп алымнар кулланды, балалар теләп шөгыльләнде. Алар куп беләләр, активлар, алдан әзерлек куп булганы сизелә. Тәрбияченең сөйләме матур, тыныч, балаларны кызыксындырып торабелә”.
- № 6 балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе Хаернасова В.: “Тәрбияче аңлаешлы итеп сорау бирә, артык сүзләр белән чуарламый. Шөгыль эчтәлеге кызыклы һәм аңлаешлы балалар өчен”.
- район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Хисматуллина Л.Ф.: “ИЗО элементлары кертелгән шөгыль катлаулы була, шуңа күрә методиканы да игътибарга алырга кирәк”.

2 нче шөгыльне Ю.В. Гильмуллина мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән “Волшебный остров” дип исемләнгән инглиз телендә күрсәтте.

Анализ:

- Меңнәр балалар бакчасы мөдире: “Тәрбияченең сөйләм теле матур, ягымлы. Шөгыль инглиз телендә булуга карамастан, балалар бик теләп катнаштылар, аңлап җавап бирделәр, бик уңышлы килеп чыкты. Балалар өчен дә кызыклы булды.”
- № 2 балалар бакчасы мөдире Ләйсән Рависовна.: “Тәрбияче шөгылне ике телдә алып барды, уен формаларын күп алган, балалар теләп шөгыльләнделәр”.
- Район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Хисматуллина Л.Ф.: “Тәрбияче балаларның аваз әйтелешен контрольдә тота, тулы җөмләләр белән сөйләүләрен дә искәртеп тора”.

3 нче эшчәнлекГ.Н. Хазиева “Профессиональный стандарт педагога”дигән темада мастер-класс күрсәтте. Район педагоглары кызыксынып карадылар, кызыклы мастер-класста катнаштылар, фикерләре, белемнәре белән уртаклаштылар.

4 нче шөгыльне И.И. Галиева “Сәламәт яшим дисәң...” дигән темага мәктәпкә әзерлек төркеме һәм коллектив белән курчак театры курсәтте.

Анализ:

- Яхшый балалар бакчасы мөдире Гөлнара: “Театр эшчәнлеге күрсәттеләр, бик уңышлы килеп чыкты. Балалар өчен дә кызыклы булды. Тәрбиячеләр куп кырлы эш эшләгәннәр”.
- № 7 балалар бакчасы мөдире Харисова А.М.: “Балалар бакчасы коллективы да, балалар да чын артистларча театр күрсәттеләр. Кулланган материаллары зәвыклы, матур”.

5 нче эшчәнлек: “Актаныш – туган җирем” – Районпедагогларына коллектив тарафыннан оештырылгантеатрлҗләштерелгәнкүңел ачу каралды.

3 көн тәртибе буенча “Балалар бакчсында һөнәри стандартлар таләбен тормышка ашыру” дигән темага өлкән тәрбияче Галиева И.И. эш тәҗрибәсе белән уртаклашты (презентация).

4 нче көн тәртибе буенчарайон мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методистХисматуллина Л.Ф. сүз алды:

- Профстандартларга кереп киттек, тиешенчә документларны өйрәнеп, эшләп куярга;
- 5-көнлеккә күчкән балалар бакчаларына тиешенчә документларны эшләп сайтларга урнаштырып бетерергә (полоҫенияләр, договорлар, соглашенияләр һ.б.);
- ЕГИССО программасына кертер өчен яңа балалар турында иформацияне вакытында биреп баруыгыз сорала;
- “Яшел ут” конкурсы положениясе сайтка куелды, эшләрне положения кысаларында гына туплау сорала;
- “Ел тәрбиячесе” конкурсы декабрь башларында булыр дип көтелә. Һәр бакчадан берәр тәрбияче, авыллар база буенча берәр сайлана.
- “Семьеведение” буенча айга бер эшчәнлек планнаштырырга кирәк;
- Электрон детсад буенча эшне даими карап барырга;
- “Билингваль балалар бакчасы” конкурсы буенча катнашырга теләге булган учрежденияләр заявка бирергә тиеш була;

Карар:

1. Профстандарт педагога буенча эшчәнлекне дәвам итәргә.
2. Планнаштырылган конкурсларда актив катнашырга.

Район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист:_________ Хисматуллина Л.Ф.
Мөдирләр РМО җитәкчесе: _____________Аглямова М.В.
Сәркатип: _____________Р. Д. Шакурова